| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«СТАРОШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИСКЕ ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2023 елның 5 июне | №21 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 06 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы (2023 елның 6 февралендәге ред.) Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә (1нче кушымта).

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юлларга.
4. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карарны, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Уставына үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң, Лениногорск районы, , Иске Шөгер авылы, Иске Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 йорт, Совет урамы буенча балалар бакчасы бинасы 3 нче йорт, М. Җәлил урамы буенча 33 нче йорт, Яңа Иске Шөгер авылы, Гагарин урамы, 1/А йорт адресы буенча буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Л.М.Шиһапова

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Советының 2023 елның 5 июнендәге 21 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Иске Шөгер авыл җирлеге» муниципаль бәрәмлеге Уставына үзгәрешләр

1) 27.1статьяда:

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пунктының гражданнар җыены тәкъдиме буенча аның составына әлеге авыл торак пункты керүче авыл торак пунктының Старостасы җирлек советы тарафыннан билгеләнә, Авыл торак пунктының Старостасы әлеге авыл торак пункты территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары йә тәкъдим ителгән көнгә 18 яшькә җиткән һәм шушы авыл торак пункты территориясендә урнашкан торак урыны булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.»;

3 өлешнең беренче абзацында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң, «үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш» сүзләрен өстәргә;

4 өлешнең 1 пунктында «муниципаль вазыйфа» сүзләреннән соң , «үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган Җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан тыш», сүзләрен өстәргә;

2) 28 статьяда:

6.2 өлештә «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

6.3 өлештә «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

28 статьяның 6.4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

3) 38 статьяда:

1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 11.2 пункт белән тулыландырырга:

«11.1) Муниципаль җирлек Советы депутаты вәкаләтләре депутат нигезле сәбәпләрсез алты ай дәвамында җирлек Советының барлык утырышларында булмаган очракта, җирлек Советы карары белән вакытыннан алда туктатыла.»;

2 өлешнең 3 абзацында «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

4) 40 статьяда:

1 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алмаштырырга;

5) 43 статьяда:

5 өлештә «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

6) 44 статьяда:

1 өлештә «Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгыы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга;

7) 47 статьяда:

1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

-халыкны элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял итүне оештыру һәм тәэмин итү өчен шартлар тудыру

- җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

-җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

-җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кыла;

- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

-җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

28) Җирлекнең коммуналь инфраструктура системаларын, җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын, таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган Җирлек социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау;

- гражданнарга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын торак законнары нигезендә бирә;»;

1 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) төзекләндерү өлкәсендә:

- адреслар бирү, адреслар үзгәртү, аннулирование, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, аннулировать итү, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә.

- Үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.

1 өлешнең 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру.";

8) 50 статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

«50 статья. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе.

1. 1. Җирлекнең сайлау комиссиясе җирлек Советына депутатлар, җирле референдум, җирлек Советы депутатын, җирлек башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүне, җирлек чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыра.

2. Сайлау комиссиясе Федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә җирлек советы тарафыннан төзелә.

Сайлау комиссиясе тәкъдимнәр нигезендә төзелә: Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлүгә рөхсәт ителгән кандидатлар исемлеген тәкъдим иткән сәяси партияләр; «Дәүләт Думасы депутатларын сайлау турында» 2005 елның 18 маендагы 51-ФЗ номерлы Федераль законның 821 статьясы нигезендә депутат мандатларын тапшырган кандидатларның федераль исемлеген тәкъдим иткән сәяси партияләр Россия Федерациясе Федераль Җыены; башка сәяси партияләр һәм башка иҗтимагый берләшмәләр; яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышы; элекке состав сайлау комиссиясе; Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе; территориаль сайлау комиссиясе.

3.Җирлек советы түбәндәгеләрдән кергән тәкъдимнәр нигезендә сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми санының яртысын билгеләп куярга тиеш:

1) Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында депутат мандатларын бүлүгә кертелгән кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән, шулай ук «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына депутатлар сайлау турында « Федераль законның $82^1$ статьясы нигезендә депутат мандатлары тапшырылган кандидатларның федераль исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләр»;

2) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән, шулай ук кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сәяси партияләрдән.

4.Сайлау комиссиясенең вәкаләтләре чоры биш ел тәшкил итә.

5. Җирлек сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш хокукына ия 6 әгъза санында төзелә.

6.Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

7.Сайлау комиссиясенең вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, Сайлау комиссиясе турындагы нигезләмә белән җайга салына. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең җирлек Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән карары буенча вәкаләтләре территория сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»